**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

"29" декабрь 2021 № 107

**Әтнә муниципаль районы Советының**
**«Әтнә муниципаль районының 2021 елга**
**һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына**
**бюджеты турында»гы 2020 елның 15 декабрендәге**
**27нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Гыймадиев Ф.И. докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1). 1,3,5,10 һәм 12нче статьяларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1нче Статья

1. 2021 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләме 500676,8 мең сум күләмендә;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 533658,6 мең сум.;

в) Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгы 32981,8 мең сум.

2. 2021 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3нче Статья

Әтнә муниципаль районы бюджетында 2021 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

5нче Статья

1. Әтнә районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә 2021 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программа булмаган эшчәнлек юнәлешләре) буенча бүлүне үзгәртергә.

2. 2021 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының ведомство структурасын әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

10нчы Статья

Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 11 нче кушымта нигезендә бүлү юлы белән 2021 елда Әтнә муниципаль районы бюджетында үзгәртергә.

12нче Статья

2021 елга Әтнә муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 8500 мең сум күләмендә расларга, 2022 елга 8700 мең сум күләмендә һәм 2023 елга 8700 мең сум күләмендә расларга һәм аларны муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәрен төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту, ишегалды территорияләрен капиталь ремонтлау һәм ремонтлау буенча чараларны тормышка ашыруга юнәлдерергә.

2) Әтнә район башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарын расларга:

05.10.2021 елдагы № 415; 28.10.2021 елдагы № 442; 02.11.2021 елдагы № 448.;

01.12.2021 елдагы № 487; 17.12.2021 елдагы № 547; 22.12.2021 елдагы № 571.

3) Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе Г.Г.Хәкимов